ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2021 Олы Кайбыч ав. № 535

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 543 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 543 номерлы карары (2019 елның 11 июнендәге 275 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшләре тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгате йә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исемен, йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, йә тиешле затның вазыйфасын ,шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), аның буенча мөрәҗәгать адресларын, шәхси имзасын һәм мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамәне, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы яисә электрон почта адресын үз эченә алырга тиеш.»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1.2.1 пунктын өстәргә:

«1.2.1. Органга яисә вазыйфаи затка кергән, тәкъдим, гариза яисә шикаять булган, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган мөрәҗәгать, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә, шул исәптән суд карарын шикаять итү тәртибен аңлату белән, җавап «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы таләпләре үтәлгән килеш, Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

Җавабы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган язма мөрәҗәгать Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать юллаган очракта, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарын шикаять итүне үз эченә алган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.»;

1.3. 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын мөмкин булган бозу фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Президентына теркәлгән көннән алып биш көн эчендә юллана.»;

1.4. 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Язма мөрәҗәгать текстын укып булмаган очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аларның компетенцияләре нигезендә орган яисә вазыйфаи затка карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, әгәр аның фамилиясе һәм җавап җибәрелергә тиеш адресын укып булса, мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аларның компетенцияләре нигезендә орган яисә вазыйфаи затка карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.»;

1.5. 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле адресы (почта адресы яисә электрон почта адресы) күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы башкарылган яисә әзерләнүче эш турында, шулай ук аны башкарган яисә башкарачак зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.»;

1.6. 3.4 пунктта «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2016 елның 25 июлендәге 49 номерлы карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 17 сентябрендәге 130 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 4.2 пунктының беренче абзацында «массакүләм мәгълүмат чаралары» сүзләрен «һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 4.6 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгатенең асылын җентекләп тикшерергә тиеш. Телдән мөрәҗәгатьтә шәхси кабул итү барышында бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык күренеп тора һәм өстәмә тикшерү таләп итми торган очракта, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тарафыннан телдәнбирелергә мөмкин, бу шәхси кабул итү карточкасында мөрәҗәгать итүченең шәхси имзасы белән раслана. Гражданның

телдән җавапка ризалыгы булмаган яисә мондый ризалык турында шәхси имзасы белән расланудан баш тарткан очракта, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.»;

1.9. 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау, шулай ук билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча актуаль мәсьәләләр буенча аңлатмалар Башкарма комитет эшчәнлеге турында еллык хисапларда чагылдырыла һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге 3 нче кушымтада бирелә торган форма буенча рәсми сайтына урнаштырыла.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр идарәчесе Д.А. Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А. Н. Макаров